**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 сентябрь № 722

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе тәртибе турында» 2002 ел, 5 сентябрь, 524 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе тәртибе турында» 2002 ел, 5 сентябрь, 524 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 18 апрель, 212 нче карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясын тормышка ашыру максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын рәсми бастырып чыгару дип, аларның тулы текстларын беренче тапкыр «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы»нда бастырып чыгару яки беренче тапкыр «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру (бастыру) исәпләнә. Шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару дип, аларның тулы текстларын «Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталында» (www.pravo.gov.ru) урнаштыру (бастыру) исәпләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\722.docx